Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Кощаково авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Кощаково авыл җирлеге Кощаково авылы
Афанасьев урамы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

12 ноябрь, 2023 ел № 3

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлеге Кощаково авылы Афанасьев урамы гражданнарының 2023 елның 12 ноябрендәге җыены беркетмәсе нигезендә түбәндәгеләр ачыкланды:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм гражданнар җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 101 (йөз бер).

- халык җыены эшендә катнашкан гражданнарның гомуми саны 52 (илле ике).

- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми сан 52 (илле ике).

- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 0 (ноль).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 6 өлеше нигезендә **гражданнар җыены мәсьәләсе буенча карарын**, түбәндәге мәсьәлә буенча «Сез 2024 елда Кощаково авылы Афанасьев урамы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 5000 сум күләмендә үзара салым кертүгә җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- юлларны ремонтлау» **кабул ителгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Кощаково авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

Кощаково авыл җирлеге башлыгы З.Н. Саттарова